| Республика Татарстан<br>Исполнительный комитет<br>Александровского сельского<br>поселения Сармановского<br>муниципального района | Татарстан Республикасы<br>Сарман муниципаль<br>районының Александровка<br>авыл җирлеге башкарма<br>комитеты |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17 июль 2020 ел № 7

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Александровка авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан 2015 елның 21 декабрендәге 16 номерлы карары белән расланган муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында

«Федераль мәгълүмат адреслы системасы турында һәм Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2019 елның 26 июлендәге 227-ФЗ номерлы Федераль законы, «Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып баруы турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законы, «Россия Федерациясе Җир кодексына һәм «Аквакультура (балыкчылык) турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 27 декабрендәге 502-ФЗ номерлы Федераль законы, Сарман муниципаль районының «Александровкаавыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә, карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Александровкаавыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан 2015 елның 21 декабрендәге 16 номерлы карары белән расланган муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларына кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.
2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Сарман муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Александровкаавыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе А.Р.Гафиятуллин